| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.11.2020 Казан ш. № 722-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 27.01.2020 № 47-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә боерам:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 27.01.2020 № 47-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
19.11.2020 № 722-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 27.01.2020 № 47-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган
үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3.2 подпунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Аренда, дәүләт мөлкәтен сату һәм инвестиция проектлары бүлеге (алга таба – БҮлек): 221-40-23.»;

1.3.5 подпунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгълүмати стендларга һәм Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирелгән мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (подпунктта) дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне көйләүче норматив хокукый актлар исемлеге (реквизитлары һәм рәсми басылу чыганаклары күрсәтелеп) «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.9 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны – Татарстан Республикасының муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге № 1376 карары белән расланган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк

эшчәнлеген оештыру тәртипләренең 34 нче пункты нигезендә оештырылган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис) (алга таба – МФЦның ерактагы эш урыны);»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) - «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль законның (алга таба - № 210-ФЗ Федераль закон) 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау. Гаризаларның киңәш ителгән формалары әлеге Регламентның 1 - 4 кушымталарында китерелгән.»;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 294, 296, 299 ст. - (алга таба – РФ ГК);

«Автоном учреждениеләр турында» 3 ноябрь 2006 ел № 174-ФЗ Федераль законның 3 ст. (алга таба – № 174-ФЗ Федераль закон);

«Татарстан Республикасы милке белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 ел, 26 июль, № 35-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 2, 7 ст. (алга таба – ТР Законы № 35-ЗРТ)

«Дәүләти һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 14 ноябрь 2002 ел № 161-ФЗ Федераль законның 11, 13 ст. (алга таба - Федераль закон № 161-ФЗ);

«Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 январь, № 7-ФЗ Федераль законның 9.2, 25 ст. (алга таба – Федераль закон № 7-ФЗ);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәнең 3.3.4, 3.3.31, 3.3.32, 3.3.34, 3.3.35, 4.1.9 пунктларыы (алга таба – Мнистрлык турында нигезләмә)»;

«Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 30 август, № 628 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестры турындагы нигезләмә (алга таба - Реестр турында нигезләмә);

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 1. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында яисә оператив идарә хокукында шуның балансында торган гариза бирүчегә беркеткәндә түбәндәгеләр кирәк:<br>- гариза (Кушымта № 1);<br>- баш бухгалтер таныклаган беренчел-торгызылу һәм соңгы отчет датасына калдык бәясен раслаучы белешмә яисә баш бухгалтер таныклаган бухгалтер балансы күчермәсе, мөһер;<br>- беркетелә торган милек исемлеге кәгазь һәм «doc, docx, xml» форматтагы электрон халәттә:<br>казна һәм автоном учреждениеләр, унитар предприятиеләр, казна предприятиеләре өчен – 1 данә, тегелгән, номерлар сугылган, оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтер имзалаган;<br>бюджет учреждениеләре өчен - 1 данә, тегелгән, номерлар сугылган, учреждение җитәкчесе һәм баш бухгалтер имзалаган, учреждениене гамәлгә куючы раслаган.<br><br>**Автоном һәм бюджет учреждениеләре өчен өстәмә:**<br>Аеруча кыйммәтле күчемле милек төрләрен билгеләү турында учреждениене гамәлгә куючы боерыгы күчермәсе. | Министрлык турында нигезләмәнең 3.3.31, 3.3.34 п.<br><br>«Дәүләти |

| | | |
|---|---|---|
| | | (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерү белән бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.05.2010 № 83-ФЗ Федераль Законны Татарстан Республикасындагы дәүләт учреждениеләрен булдыру, үзгәртеп оештыру, төрен үзгәртү һәм бетерү ягыннан тәртип урнаштыру, шулай ук, Татарстан Республикасындагы дәүләт учреждениеләрен |

| | | |
|---|---|---|
| | | гамәлгә куючының һәм мөлкәт иясенең функцияләрен һәм вәкаләтләрен регламентацияләү ягыннан Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.10.2010 № 820 карарының 1 п. (алга таба – ТР МК карары № 820);<br>«Татарстан Республикасы автоном яки бюджет учреждениесенең аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәте төрләрен һәм исемлекләрен |

| | | |
|---|---|---|
| | **Мәдәни мирас объектларын беркеткән очракта өстәмә рәвештә:**<br>Татарстан Республикасы милкендә булган мәдәни мирас объектын саклау буенча кулланучының йөкләмәләре күчермәсе. Аны түбәндәгеләр формалаштыра:<br>мәдәни мирас объектын саклау өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы – федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына (башкарма хакимиятнең массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә контроль һәм күзәтү функцияләрен башкаручы федераль органы белән килештерү буенча) һәм региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына мөнәсәбәтле;<br>муниципаль районның һәм шәһәр округының башкарма комитеты – җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына мөнәсәбәтле.<br><br>2. **Яңа алынган мөлкәтне хуҗалык итү хокукында яисә оператив идарә хокукында гариза бирүчегә беркеткәндә түбәндәгеләр сорала:**<br>- гариза (2 нче кушымта);<br>- Кәгазь һәм «doc, docx, xml» форматтагы электрон халәттә тапшырылган һәм мөлкәт сатып алынган акча | билгеләү тәртибе турында” 22.10.2010 № 848 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 3 п. (алга таба – ТР МК карары № 848);<br>Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) турында» 2002 ел, 25 июнь, 73-ФЗ номерлы Федераль законның $47^6$, 48 ст. (алга таба - Федераль закон № 73-ФЗ)<br><br><br><br>Федераль закон<br>№ 161-ФЗ;<br>Федераль законның |

| | | |
|---|---|---|
| | чыганагы күрсәтелгән беркетелә торган милек исемлеге.<br><br>**Дәүләт учреждениеләре өчен өстәмә рәвештә:**<br>Беркетелә торган мөлкәт исемлеге гамәлгә куючы белән килештерелгән булырга тиеш.<br><br>**Автоном һәм бюджет учреждениеләре өчен өстәмә рәвештә:**<br>Аеруча кыйммәтле күчемле милек төрләрен билгеләү турында гамәлгә куючы боерыгы күчермәсе.<br><br>3. **Эксплуатациягә яңа кертелгән мөлкәтне хуҗалык итү хокукында яисә оператив идарә хокукында** гариза бирүчегә беркеткәндә түбәндәгеләр сорала:<br>- гариза (3 нче кушымта);<br>- объектны төзү рөхсәте күчермәсе;<br>- объектны эксплуатациягә кертү рөхсәте күчермәсе;<br>- Кәгазь һәм «doc, docx, xml» форматтагы электрон халәттә тапшырылган, беркетелә торган милекнең гамәлгә куючы белән килештерелгән исемлеге;<br>- мөлкәт төзелешенең заказчысы мөрәҗәгате;<br>- мөлкәтне кабул итеп алу – тапшыру акты проекты.<br><br>4. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне башка дәүләт предприятиесенең (дәүләт учреждениесенең) | № 7-ФЗ 9.2, 25 ст.;<br>№ 35-ЗРТ ТР Законының 4 ст.;<br>Реестр турында нигезләмәнең 1.3, 1.4 п.;<br>Министрлык турында нигезләмәнең 3.3.31, 3.3.34 п.;<br><br><br>ТР МК № 820 карарының 1 п.;<br>ТР МК № 848 карарының 3 п.;<br><br>№ 161-ФЗ Федераль закон;<br>№ 7-ФЗ Федераль закон 9.2, 25 ст.;<br>ТР МК № 820 карарының 1 п.;<br>ТР МК № 848 |

| | | |
|---|---|---|
| | **хуҗалык итү хокукыннан яисә оператив идарә хокукыннан алып,** хуҗалык итү хокукында яки оператив идарәдә гариза бирүчегә **беркеткәндә** түбәндәгеләр сорала:<br>- гариза (4 нче кушымта);<br>- баш бухгалтер таныклаган беренчел-торгызылу һәм соңгы отчет датасына калдык бәясен раслаучы белешмә яисә баш бухгалтер таныклаган бухгалтер балансы күчермәсе, мөһер;<br>- беркетелә торган милекнең кәгазь һәм «doc, docx, xml» форматтагы электрон халәттә исемлеге:<br>- казна һәм автоном учреждениеләр, унитар предприятиеләр өчен – 1 данәдә, тегелгән, номерлары сугылган, оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтер имзалаган булырга тиеш;<br>- бюджет учреждениеләре өчен - 1 данәдә, тегелгән, номерлары сугылган, учреждениене гамәлгә куючы раслаган оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтер имзалаган булырга тиеш.<br><br>**Казна учреждениеләре өчен өстәмә:**<br>тапшыра торган якның гамәлгә куючысының милекне алдыруга ризалыгы;<br>гамәлгә куючының гариза бирүчегә милекне беркетергә ризалыгы. | карарының 3 п;<br>№ 7-ФЗ Федераль законның 27 ст.;<br>№ 35-ЗРТ ТР Законының 4 ст.;<br><br>Реестр турында нигезләмәнең 1.3, 1.4 п.;<br>Министрлык турында нигезләмәнең 3.3.31, 3.3.34 п.;<br><br>№ 161-ФЗ Федераль закон;<br>№ 7-ФЗ Федераль законның 9.2, 25 ст.;<br>Министрлык турында нигезләмәнең 3.3.14 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| | **Автоном, бюджет учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре өчен өстәмә рәвештә:**<br>тапшыра торган якның милекне алдыруга ризалыгы.<br><br>**Автоном учреждениеләр өчен өстәмә рәвештә:**<br>автоном учреждениенең багучылар шурасының автоном учреждениенең мөлкәтен алу турында карары.<br><br>**Балалар өчен социаль инфраструктура объекты булган учреждениеләр өчен өстәмә рәвештә:**<br>җитәкче кул куйган һәм учреждениене гамәлгә куючы белән килештерелгән мөлкәтнең алыну нәтиҗәләре турында эксперт бәяләмәсе (мәгариф учреждениеләре һәм балалар медицина учреждениеләре өчен Федераль агентлыкның 24.03.2006 ел №16-55-88ин/02-12 хаты белән расланган форма буенча).<br><br>**Мәдәни мирас объектларын беркетү очрагында өстәмә рәвештә:**<br>Татарстан Республикасы милкендә булган мәдәни мирас объектын саклау буенча кулланучының йөкләмәләре күчермәсе. Аны түбәндәгеләр формалаштыра:<br>Мәдәни мирас объектын саклау өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы – федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына | № 161-ФЗ Федераль закон;<br>№ 7-ФЗ Федераль законның 9.2, 25 ст.;<br>№ 174-ФЗ Федераль законның 11 ст.;<br>ТР МК № 820 карарының 1 п.;<br>ТР МК № 848 карарының 3 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| | (башкарма хакимиятнең массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә контроль һәм күзәтү функцияләрен башкаручы федераль органы белән килештерү буенча) һәм региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына мөнәсәбәтле;<br>муниципаль районның һәм шәһәр округының башкарма комитеты – җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына мөнәсәбәтле;<br>кабул итеп алу – тапшыру акты проекты.<br>Юридик затларның вәкилләре персональ мәгълүматны эшкәртергә язмача ризалык бирә (6 нчы кушымта).<br>Барлык документларның күчермәсе 1 данәдә тапшырыла һәм юридик зат җитәкчесе тарафыннан таныклана.<br>Гаризага теркәлгән документлар төп нөсхәдә (документларга үтеп керү мөмкинлеге булган очракта күчермәләре) бирелә (юллана), яисә җир кишәрлегенә хокуклар алу турында мөрәҗәгатьне кабул итеп алучы Министрлык белгече тарафыннан таныкланган күчермәләрдә.<br>Гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин.<br>Гариза һәм аңа беркетелгән документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьгә бастырылып түбәндәге ысуллар белән тапшырыла (җибәрелә) ала:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә | Министрлык турында нигезләмәнең 4.1.9 п.;<br><br>№ 73-ФЗ Федераль законның $47^6$ ст.»; |

| | | |
|---|---|---|
| | нигезендә эш итүче тарафыннан);<br>почта аша.<br>Гариза һәм аңа теркәлгән документлар, техник мөмкинлекләр булганда, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга «Электрон имза турында» 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 63-ФЗ Федераль закон) һәм 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора | |

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпләр атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомствосында булган оешмаларда сакланган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар карамагында сакланган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма»;

2.8 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

Түбәндәге шартларның берсенең генә булса да булуы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

1) милек белән эш итүнең башка тәртипләрен күздә тоткан карарларны тиешле тәртиптә кабул ителүе;

2) бу милек белән эш итүнең башка тәртипләрен күздә тоткан законлы көченә кергән суд карары;

3) гариза бирүче тапшырган документларда ниндә дә булса белешмәләрнең булмавы яки дөрес түгел белешмәләр булуы.»;

2.12 пунктта «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы, 1 п.»;

2.14 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы урнаштырылган, документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар куелган Министрлык бинасында һәм бүлмәләрендә башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текст форматында һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән, инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуы да күздә тотыла.

Инвалидларны, шул исәптән, кресло-арба һәм озатып йөрүче эт куллануччыларны, объектларга үтеп керү һәм хезмәт алу мөмкинлеге белән тәэмин итү чаралары гамәлгә ашырыла. Моңа түбәндәгеләр дә керә:

бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук, аларда күрсәтелгән хезмәтләргә каршылыксыз үтү шартлары;

Министрлык территориясе буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу мөмкинлеге, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән, кресло-арба кулланып;

күз күрү һәм мөстәкыйль йөри алу функцияләре бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуны исәпкә алып, бинага, бүлмәләргә каршылыксыз керә алу һәм хезмәт күрсәтү мөмкинлеге өчен зарури җайланмаларны һәм мәгълүмат чыганакларын уңайлы урыннарда урнаштыру;

дәүләт хезмәте алу өчен зарури тавыш һәм күз күреме аша бирелгән мәгълүматны, шулай ук, язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль шрифты рельефлы-нокталы билгеләре белән кабатлау, сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге № 386н боерыгы белән расланган «Озатучы этнең махсус өйрәтелгәнен раслаучы документ формасын раслау турында, һәм аны бирү тәртипләре» белән күрсәтелгән формада һәм тәртипләрдә махсус өйрәтелгәнлеген раслаучы документ булса, озатучы этне бинага һәм бүлмәләргә кертү;

дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең инвалидларга башкалар белән бертигез дәүләт хезмәте алырга комачаулаган каршылыкларны үтәргә ярдәм итүе»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге № 181-ФЗ Федераль закон (алга таба –№ 181-ФЗ Федераль закон);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (ТР МКның 02.11.2010 № 880 карары)»;

2.15 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;

кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;

мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;

Министрлык бинасын һәм бүлмәләрне инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелгән бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыра торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү, шулай ук, инвалидларга дәүләт хезмәте алуны тәэмин итүче башка шартларны үтәү;

инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтелү өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү белән бәйле булмаган башка киртәләрне үтәргә булышу.

Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;

Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозулары турында нигезле шикаятьләрнең булмавы;

гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеш саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә бер тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артмый;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел;

Министрлык бинасының, дәүләт хезмәте күрсәтү бүлмәләренең инвалидлар керү өчен уңайлы булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү ачыклыгы күрсәткечләренә ирешү.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә белгеч белән гариза бирүченең бәйләнеш вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирү дә, күпфункцияле үзәк аша, дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны аша күрсәтелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Министрлыкка телдән (шәхсән үзе яки телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать итеп, Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша алырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы запрос буенча күрсәтелми»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Федераль закон № 181-ФЗ;

ТР МКның 02.11.2010 № 880 карары»;

3 бүлекнең 3.5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.1, 3.4.2 пунктларында күрсәтелгән белешмәләрне (документларны) алганнан соң түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерә;

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү турында Министрлык карары проектын әзерли (алга таба – Министрлык карары проекты) яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты (Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетүдән баш тарту турында хат проекты) (алга таба – баш тарту турында хат проекты) әзерли.

Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә җибәрә.

Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән шартларның берсе генә булса да, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту проекты әзерли.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар запросларга җаваплар алынганнан соң җиде эш көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: әзерләнгән һәм килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты.»;

5 бүлекнең 5.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Гариза бирүче тарафыннан бәян ителгәннәрне раслый торган документлар (булса), яки аларның күчермәләре тапшырыла ала.».

Кушымтаны (белешмәлек) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмә**

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 221 -40-00 | mzio@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Министрның беренче урынбасары | 221 -40-02 | mzio@tatar.ru |
| Дәүләт мөлкәтен файдалану бүлеге мөдире | 221-40-25 | NM.Mizakova@tatar.ru |
| Торак күчемсез мөлкәт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары бүлеге мөдире | 221-40-28 | Irina.Petruhina@tatar.ru |
| Аренда, дәүләт мөлкәтен сату һәм инвестиция проектлары бүлеге мөдире | 221-40-21 | Ilshat.Aminov@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге | 221-40-81 | Gulnur.Rumyanceva@.tatar.ru |

## Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы | 264-77-22 | Renat.Gaynutdinov@tatar.ru |
| Дәүләт мөлкәте белән эш итү бүлеге мөдире | 264-76-22 | Maksim.Rogozhkin@tatar.ru». |